КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 11 июль г.Казань № 811

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 24 декабрь, 1214 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында (муниципаль хокукый актларында), шул исәптән Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтләрен һәм Россия Федерациясе белән Татарстан Республикасының уртак карамагындагы мәсьәләләр буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда каралган, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең гомумроссия база (тармак) исемлекләренә (классификаторларына) кертелмәгән дәүләт хезмәтләре (муниципаль хезмәтләр) күрсәтүнең һәм эшләр башкаруның төбәк исемлегенә (классификаторына) үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында (муниципаль хокукый актларында), шул исәптән Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтләрен һәм Россия Федерациясе белән Татарстан Республикасының уртак карамагындагы мәсьәләләр буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда каралган, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең гомумроссия база (тармак) исемлекләренә (классификаторларына) кертелмәгән дәүләт хезмәтләре (муниципаль хезмәтләр) күрсәтүнең һәм эшләр башкаруның төбәк исемлеген (классификаторын) раслау турында» 2018 ел, 24 декабрь, 1214 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар

Кабинетының 2019 ел, 10 июль, 563 нче; 2019 ел, 16 июль, 586 нчы; 2019 ел, 5 ноябрь, 1011 нче; 2019 ел, 27 декабрь, 1222 нче; 2020 ел, 10 июнь, 480 нче; 2020 ел, 31 август, 762 нче; 2020 ел, 16 декабрь, 1143 нче; 2021 ел, 29 октябрь, 1017 нче; 2022 ел, 24 гыйнвар, 44 нче; 2022 ел, 10 май, 426 нчы; 2022 ел, 15 июль, 677 нче; 2022 ел, 4 август, 757 нче; 2022 ел, 11 ноябрь, 1202 нче; 2023 ел, 3 март, 201 нче; 2023 ел, 1 июнь, 669 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында (муниципаль хокукый актларында), шул исәптән Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтләрен һәм Россия Федерациясе белән Татарстан Республикасының уртак карамагындагы мәсьәләләр буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда каралган, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең гомумроссия база (тармак) исемлекләренә (классификаторларына) кертелмәгән дәүләт хезмәтләре (муниципаль хезмәтләр) күрсәтүнең һәм эшләр башкаруның төбәк исемлегенә (классификаторына) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

13.1 пунктның 18 графасындагы 3 пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга;

14.4 пунктның 3 графасында «яраклы эш эзләүдә булышлык күрсәтү максатларында гражданнарны теркәү, шулай ук эшсез гражданнарны теркәү» сүзләрен төшереп калдырырга;

14.5 пунктта:

2 графаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Яраклы эш эзләү максатларында теркәлгән гражданнарга профиль бирү (аларның элеккеге һөнәри эшчәнлеге өлкәсенә, җенесенә, яшенә һәм башка социаль-демографик тасвирнамәләренә, шулай ук хезмәт базарындагы статусына, эшкә урнашу потенциалына һәм эшкә урнашу мотивациясенә карап, әлеге гражданнарны төркемнәргә бүлү), шулай ук халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәткәндә әлеге гражданнарга һәм эш бирүчеләргә хезмәт базарында барлыкка килә торган вәзгыятьне исәпкә алып эффективлы ярдәм күрсәтү максатларында эш бирүчеләргә профиль бирү (оештыру-хокук формасына, икътисадый эшчәнлек төренә, финанс-икътисадый хәлгә, хезмәт шартларына, эш хакы дәрәҗәсенә һәм башка тасвирнамәләргә карап, эш бирүчеләрне төркемнәргә бүлү) буенча махсус чаралар оештыру һәм үткәрү»;

3 графада «эшсез гражданнаргә профиль бирү (эшкә урнашуда булышлык иткәндә, хезмәт базарында барлыкка килә торган вәзгыятьне исәпкә алып, аларга эффективлы ярдәм күрсәтү максатларында, эшсез гражданнарның элеккеге һөнәри эшчәнлеге өлкәсенә, белем дәрәҗәсенә, җенесенә, яшенә һәм башка социаль-демографик тасвирнамәләренә карап, әлеге гражданнарны төркемнәргә бүлү) буенча махсус чаралар оештыру һәм үткәрү» сүзләрен төшереп калдырырга;

14.6 пунктның 3 графасында «Россия Федерациясе субъектында халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтелүчеләр регистрларын булдыру һәм алып бару» сүзләрен төшереп калдырырга;

14.9 пунктның 2 графасында «җибәрү» сүзен «әзерләү һәм җибәрү» сүзләренә алмаштырырга;

14 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 14.10 һәм 14.11 пунктлар өстәргә:

| | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «14.10. | Эш бирүчеләргә хезмәт ресурсларының мобильлеген арттыру буенча төбәк программаларын тормышка ашыру кысаларында хезмәт ресурсларын җәлеп итүдә булышлык күрсәтү | | | | эш | дәүләт эше бушлай | 78.30; 84.13; 84.30; 88.99 | 03.07.2018 | 31.12.2099 | Татарстан Республикасы | казна | кирәкле хезмәткәрләрне сайлап алуда эш бирүчеләргә булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен мөрәҗәгать иткән эш бирүчеләр | эш бирүчеләр саны, берәмлек | | нет | нет | 1) «Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» 1991 елның 19 апрелендәге 1032-1 номерлы Россия Федерациясе Законы ($7^{1-1}$ статья);<br>2) «Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында» 2006 елның 19 июнендәге 39-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы ($2^1$ статья) |
| 14.11. | Инвалидларны эш белән тәэмин итүдә ярдәм күрсәткәндә булышлык күрсәтеп тору мәсьәләләре буенча эш бирүчеләргә мәгълүмат бирүне гамәлгә ашыру | | | | эш | дәүләт эше бушлай | 78.30; 84.13; 84.30; 88.99 | 08.12.2018 | 31.12.2099 | Татарстан Республикасы | казна | кирәкле хезмәткәрләрне сайлап алуда эш бирүчеләргә булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен мөрәҗәгать иткән эш бирүчеләр | мәгълүмат бирелгән эш бирүчеләр саны, берәмлек | | нет | нет | 1) «Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында» 2006 елның 19 июнендәге 39-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы ($2^1$ статья)». |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин